**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.07.2024 **Чирмешән авылы** №258

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча регламентны раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 324 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге № 685-ФЗ Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар» күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча регламентны раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 324 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлекнең 1 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Тәрбия - бу шәхесне үстерүгә, социокультур, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре һәм Россия җәмгыятендә кабул ителгән кеше, гаилә, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә укучыларның үзбилгеләнүе һәм социализациясе өчен шартлар тудыруга, укучыларда патриотизм, гражданлык хисе, Ватанны саклаучылар истәлегенә һәм Ватан геройларының батырлыкларына, законга һәм хокук тәртибенә, хезмәт кешесенә һәм өлкән буынга хөрмәт, үзара хөрмәт, Россия Федерациясенең күпмилләтле халкының мәдәни мирасына һәм традицияләренә, табигатенә һәм әйләнә-тирә мохитенә сакчыл караш формалаштыруга юнәлдерелгән эшчәнлек.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов